ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2019 Олы Кайбыч авылы № 404

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11гыйнварында чыккан 7 номерлы «2019 елда халык, бюджет һәм башка оешмалар өчен торак – коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 156, 158 статьялары, 2003 елның 6 октябрендә чыккан 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11гыйнварында чыккан 7 номерлы «2019 елда халык, бюджет һәм башка оешмалар өчен торак – коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт һәм муниципаль торак фондыннан торак бинаны кулланган өчен социаль найм килешүе һәм торак бина наймы килешүе буенча, бинаны карап торган өчен түләү күләме (найм өчен түләү) һәм күпфатирлы йорт идарәсе турында карар кабул итмәгән торак бина милекчеләре өчен торак бинаны карап тору өчен түләү күләме (1нче кушымта);»;

1нче кушымта атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль торак фондыннан торак бинаны кулланган өчен социаль найм килешүе һәм торак бина наймы килешүе буенча, бинаны карап торган өчен түләү күләме (найм өчен түләү) һәм күпфатирлы йорт идарәсе турында карар кбул итмәгән торак бина милекчеләре өчен торак бинаны карап тору өчен түләү күләме».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров